КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 30 декабрь г.Казань № 1286

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 2 август, 747 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасыннан катнашучыларны төрле дәрәҗәдәге «Ворлдскиллс» стандартлары буенча чемпионатларга әзерләү өлешендә устав эшчәнлеген, «Ворлдскиллс» стандартлары нигезендә чараларны оештыруны финанс белән тәэмин итүгә коммерциягә карамаган оешмаларга субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасыннан катнашучыларны төрле дәрәҗәдәге «Ворлдскиллс» стандартлары буенча чемпионатларга әзерләү, «Ворлдскиллс» стандартлары нигезендә чараларны оештыру өлешендә устав эшчәнлеген финанс белән тәэмин итүгә коммерциягә карамаган оешмаларга субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 2 август, 747 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 29 декабрь, 1438 нче; 2023 ел, 24 апрель, 520 нче, 2024 ел, 26 октябрь, 927 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасыннан катнашучыларны төрле дәрәҗәдәге «Ворлдскиллс» стандартлары буенча чемпионатларга әзерләү өлешендә устав эшчәнлеген, «Ворлдскиллс» стандартлары нигезендә чараларны оештыруны финанс белән тәэмин итүгә коммерциягә карамаган оешмаларга субсидия бирү тәртибенә, аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә (карарга теркәлгән).

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин